ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЕНАБЕРДИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ
ЕНАБЕРДИНО АВЫЛЫНДА
ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

2019 елның 23 ноябреннән № 2

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Енабердино авыл җирлегенең
Енабердино авылында гражданнар җыены
нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлегенең Енабердино авылында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. 2018 елда Енабердино гомуми белем бирү мәктәбе территориясенә һәйкәл күчерүгә каралган 387500 сум акча средстволарын Бөек Ватан сугышында катнашучыларга куелган һәйкәлне ремонтлауга, һәйкәл тирәсен төзекләндерүгә һәм коймаларны алыштыруга, шулай ук һәйкәл каршындагы санкцияләнмәгән юлны сүтүгә тотарга.

2. Енабердино авылы, Клуб урамы, 7 нче йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендына урнаштыру юлы белән әлеге карарны игълан итәргә, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Енабердино авыл җирлеге башлыгы Е.Н.Никифоров